СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2022 г.Зеленодольск № 174

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия турында нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- 2014 елның 31 мартындагы 374 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында»;

- 2015 елның 5 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 374 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында»гы 498 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск

муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск
муниципаль районы Советы
карарына
кушымта
2022 елның 20 маендагы
174 номерлы карары

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында (алга таба – район җирле үзидарә органы) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия (алга таба – Конкурс комиссиясе) эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Конкурс комиссиясе даими эшләүче орган булып тора һәм үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында килешүләр, вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру вәкаләтләрен тапшыру турындагы килешүләр, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Конкурс комиссиясе составы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән төзелә (алга таба – район Башлыгы).

4. Конкурс комиссиясе әгъзалары саны 7 кеше тәшкил итә, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы вәкилләре һәм (яки) бәйсез экспертлар арасыннан 2 кеше.

Конкурс комиссиясе Конкурс комиссиясе рәисеннән, урынбасарыннан, секретарьдән һәм әгъзаларыннан тора (алга таба – Конкурс комиссиясе әгъзалары).

5 Конкус комиссиясе составына район Башлыгы урынбасары,, Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе һәм Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының Кадрлар сәясәте бүлегеннән район Башлыгының вәкаләтле вәкилләре муниципаль хезмәткәрләре, Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге, вакантлы вазыйфасы булган, конкурс игълан ителгән Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирлек Башлыгы) (муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган, вакантлы вазыйфасы

буенча кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирлек Башлыгы) , шулай ук фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре, район Башлыгы соравы буенча Конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан, экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә генә, бәйсез экспертлар сыйфатында чакырылган муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр.

6. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен Конкурс комиссиясе составы дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

7. Конкурс комиссиясе составы Конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген булдырмаслык итеп төзелә.

Конкурс комиссия әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килгән яисә барлыкка килү ихтималы булганда, аның Конкурс комиссиясе составында әгъзалыгы күрсәтелгән Конкурс комиссиясе эше чорына, Конкурс комиссиясе әгъзасының язма гаризасы нигезендә, мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кадәр йә аның барлыкка килү мөмкинлеген булдырмас өчен туктатылып торыла.

8. Конкурс комиссиясе әгъзалары комиссия эшендә җәмәгать башлангычларында катнашалар.

## II. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары һәм функцияләре

9. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) район җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс оештыру һәм үткәрү;

2) Зеленодольск муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру һәм нәтиҗәле файдалануны оештыру;

3) Зеленодольск муниципаль районы составына керүче район җирле үзидарә органнары эшчәнлеген кадрлар составын формалаштыру буенча координацияләү;

4) кадрлар резервын формалаштыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү.

5. Үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә Конкурс комиссиясе түбәндәге функцияләрне башкара:

1) Зеленодольск муниципаль районы составына керүче район җирле үзидарә органнарында, җирлекләрдә муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфаларын (муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларны һәм вакантлы идарә вазыйфаларын кадрлар резервына кертү) биләп торуга дәгъвачыларны конкурс нигезендә конкурска сайлап алуны үткәрү;

2 претендентларның һәркайсын балл бәяләве системасына нигезләнгән претендентларны конкурс нигезендә конкурска сайлап методикасын раслау;

3) җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар резервына ия булган белгечләргә ихтыяҗын ел саен бәяләү уздыру.

## III. 2. Конкурс комиссиясенең хокуклары һәм бурычлары

10. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Конкурс комиссиясе түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җирле үзидарә органнарыннан Конкурс комиссиясе эше өчен кирәкле мәгълүматларны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга һәм алырга;

2) район Башлыгына конкурс комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә.

11. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Конкурс комиссиясе түбәндәгеләргә бурычлы:

1) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре һәм гражданнарны кадрлар резервыннан төшереп калдыру турында гражданнарга һәм җирле үзидарә органнарына мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

2) конкурста катнашу өчен дәгъвачыларның алдан исемлеген формалаштыру максатларында җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документларны һәм материалларны карарга һәм бәяләүне үткәрергә;

3) претенденттан претендентның үзе тәкъдим иткән анкетада күрсәтелгән персональ мәгълүматларын кулланууга язмача ризалык алу;

4) конкурс сайлап алуының беренче этабын үткәрү нәтиҗәләре буенча, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмә һәм Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарә вазыйфаларын һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмә белән каралган карарларның берсен кабул итәргә, һәм аның турында тиешле җирле үзидарә органнарына претендентлар сайлап алуның икенче этабын уздыруга 15 календарь көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә

5) дәгъвачылар арасыннан һәрберсенең йомгаклау баллын билгеләү юлы белән дәгъвачыларны конкурска сайлап алуның икенче этабында бәяләү үткәрү;

6) конкурс сайлап алуының икенче этабында катнашучы дәгъвачыларны кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә.

## IV. Конкурс комиссиясенең эш тәртибе

12. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне Конкурс комиссиясе рәисе башкара.

Конкур комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе эшенә гомуми җитәкчелек итә, аның утырышларын үткәрә, аның әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, комиссия утырышын үткәрү урынын һәм вакытын билгели, Конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә, утырыш беркетмәләренә кул куя, үз компетенциясе кысаларында комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота, вакантлы вазыйфаларны биләүгә (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме буенча) конкурста катнашуга кертелгән гражданнарның (муниципаль хезмәткәрләрнең) һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын куллану зарурлыгын һәм чиратлылыгын билгели .

Конкурс комиссиясе рәисе вакытлыча булмаган чорда аның эшчәнлеген Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары алып бара.

Конкурс комиссиясе секретаре Конкурс комиссиясе эшен, шул исәптән, түбәндәгеләрне тәэмин итә:

1) конкурс игълан итү турында район Башлыгы күрсәтмәсен әзерли;

2) Интернет челтәренең Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Россия Федерациясе граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан, шулай ук конкурс игълан ителгән көннән алып 7 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс турында мәгълүматларны урнаштыруны тәэмин итә;

3) конкурста катнашу өчен документлар тапшырган затларны исәпкә алып бара;

4) конкурс үткәрүне оештыра;

5) конкурсның икенче этабы турында рәсми сайтларда, 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә, кандидатларга тиешле хәбәрләр җибәрә;

6) Конкурс комиссиясе утырышы алдыннан, 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә;

7) Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен алып бара;

8) конкурс сайлап алуының икенче этабында претендентлар җыйган балларны санауны гамәлгә ашыра;

9) 5 эш көне эчендә утырышта катнашучы барлык Конкурс комиссиясе әгъзаларыннан беркетмәгә кул куйдыра;

10) конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына конкурс җиңүчесен билгеләү (кадрлар резервына кертү) турында район Башлыгы күрсәтмәсе проектын әзерли;

11) конкурста катнашучы кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында 7 көн эчендә язма рәвештә хәбәр итә;

12) конкурс тәмамланганнан соң 7 көн эчендә конкурс нәтиҗәләре турында рәсми сайтларда мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә.

Конкурс комиссиясе секретаре вакытлыча булмаганда, аның бурычлары Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан Конкурс комиссиясенең бер әгъзасына йөкләнә.

Конкурс комиссиясе секретаре муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларны бәяләүдә катнаша һәм Конкурс комиссиясе карарларын кабул иткәндә тавыш бирү хокукына ия.

13. Конкурс комиссиясе утырышы, кирәк булган саен, район Башлыгының конкурс үткәрү турында күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә.

14. Конкурс комиссиясе утырышы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат (кадрлар резервына кертү өчен конкурс сайлап алуында катнашу өчен кимендә өч кандидатура) булганда уздырыла.

15. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

16. Конкурс комиссиясе тарафыннан, Конкурс комиссиясенең турыдан-туры кандидатлар белән шәхси әңгәмә үткәрмичә, конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү рөхсәт ителми.

17. Конкурс нәтиҗәләре буенча Конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез бүленгән очракта, хәлиткеч тавыш Конкурс комиссиясе рәисендә кала.

18. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына билгеләү өчен яисә бу вазыйфага билгеләнүне (кадрлар резервына кертүне) кире кагу өчен нигез булып тора.

19. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү турында нигезләмә белән расланган форма буенча Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

20. Конкурс комиссиясе тәкъдим итү характерында, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатларына югары бәя бирелгән кандидатны, җирле үзидарә органнарының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итә.

21. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс нәтиҗәләре буенча беркетмә конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән 5 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.